**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2022 Бима авылы № 14

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының «««2015-2030 елларга «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 25 ноябрындагы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокурорының 2022 елның 24 июнендәге 02-01-02-2022 номерлы «Ачыкланган коррупциоген факторларны булдырмау максатында норматив хокукый актны үзгәртү турында» таләпләрен үтәү йөзеннән, муниципаль хокукый актны норматив хокукый актлар таләпләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының «««2015-2030 елларга «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2015 елның 17 ноябрындагы 9 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Бима авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Э.И. Михайлов

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Бима авыл җирлеге
Башкарма комитетының
07.07.2022 № 14
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2016 елның 17 мартындагы 7 номерлы карарына үзгәрешләр**

Статья 1
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге Башкарма комитетының ««2015-2030 елларга «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» муниципаль озак сроклы максатчан программасын раслау турында»» 2016 елның 17 мартындагы 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.1 өлешнең 1.2 пунктының дүртенче абзацында:
«кабул ителергә мөмкин» сүзләрен «кулланыла,» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 өлешнең бишенче абзацында:
«яңадан каралырга мөмкин» сүзләрен «яңадан карала» сүзләренә алмаштырырга.